РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГӘЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Садовая, дом 17,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 2

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 1 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Гәйтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык, 2нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез элек расланган гражданнар җыенына чыгарылган сорауларга үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 03.11.2023 ел № 5 карары.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пунктында гражданнар җыены карары 03.11.2023 ел № 6,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пунктында теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2400 сум күләмендә 2024 елда үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.

2) җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр өчен җир өстендәге үтүләрне ремонтлау.

3) урам яктырту җайланмасы.

4) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

5) торак пункт территориясен төзекләндерү.

6) коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/rus/nurlat_poselenia.htm, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гәйтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева